КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 24 ноябрь г.Казань № 1117

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында санитария-эпидемиология хәлен һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 28 октябрь, 1006 нчы; 2021 ел, 29 октябрь, 1018 нче; 2021 ел, 17 ноябрь, 1100 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

унҗиденче абзацта «кемгә каравын раслап, QR-кодларын яки яңа коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) каршы вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләрен раслаган гамәлдәге шәхси QR-кодларын (алга таба – вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләре турында QR-код)» сүзләрен «кемгә каравын раслап, бу карарның 8 пунктында күрсәтелгән, бирелгән затларга гамәлдәге шәхси QR-кодларын (алга таба – республика QR-коды)» сүзләренә алмаштырырга;

унсигезенче абзацта «вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләре турында QR-кодын» сүзләрен «республика QR-кодын» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәгеләргә медицина оешмалары тарафыннан бирелә торган медицина бәяләмәләрендә (белешмә кәгазьләрендә) республика QR-кодлары булуны тәэмин итәргә:

а) яңа коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) каршы вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләренә ия затларга;

б) яңа коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) каршы ике компонентлы вакцинаның яки бер компонентлы вакцинаның беренче компоненты белән вакцинация ясаган затларга (QR-кодларның гамәлдә булу срогы – мондый вакцинация ясаган көннән 24 көн);

в) яңа коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) каршы вакцинация ясаган хәрби хезмәткәрләргә.»;

9 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) бу карарның 8 пунктында күрсәтелгән, тиешле хәлләрнең булуы республика QR-коды белән раслана торган;»;

1 нче кушымтаның 2 пунктындагы 2 пунктчасында:

дүртенче абзацта «кемгә каравын раслап, QR-кодларын яки яңа коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) каршы вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләрен раслаган гамәлдәге шәхси QR-кодларын (алга таба – вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләре турында QR-код)» сүзләрен «кемгә каравын раслап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарындагы 8 пунктында күрсәтелгән, бирелгән затларга гамәлдәге шәхси QR-кодларын (алга таба – республика QR-коды)» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләре турында QR-кодын» сүзләрен «республика QR-кодын» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар 2021 елның 26 ноябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин